3) түбəндəге эчтəлекле $11^1$ статья өстəргə:

«$11^1$ статья. **Һөнəри спорт өлкəсендə эшчəнлекне җайга салу үзенчəлеклəре**

Һөнəри спорт өлкəсендə эшчəнлекне җайга салу үзенчəлеклəре Федераль законда билгелəнə.»;

4) 12 статьяның 14 өлешендə беренче җөмлəне түбəндəге редакциядə бəян итəргə: «Россия Федерациясе йөклəмəлəре барлыкка килə торган халыкара спорт чаралары Татарстан Республикасы территориясендə бары тик аларны үткəрү турындагы карарларны тиешле спорт төрлəре буенча гомумроссия спорт федерациялəре, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һəм физик культура һəм спорт өлкəсендə федераль башкарма хакимият органы белəн килештергəннəн соң гына үткəрелə.», икенче җөмлəдə «Татарстан Республикасы территориясендə» сүзлəреннəн соң «мондый» сүзен өстəргə;

5) 14 статьяда:

а) 2 өлештə «спорт разрядлары бирү тəртибе» сүзлəрен «спорт разрядлары бирү, алардан мəхрүм итү һəм аларны кире кайтару тəртибе» сүзлəренə алмаштырырга;

б) 3 өлештə «квалификация категориялəрен бирү тəртибе» сүзлəрен «квалификация категориялəре бирү, алардан мəхрүм итү һəм аларны кире кайтару тəртибе» сүзлəренə алмаштырырга;

в) 4 өлештə «физкультура-спорт оешмалары» сүзлəреннəн соң «, спорт əзерлеген гамəлгə ашыручы оешмалар, физик культура һəм спорт өлкəсендəге эшчəнлекне гамəлгə ашыручы мəгариф оешмалары» сүзлəрен өстəргə;

6) 17 статьяны түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«17 статья. **Спортта допинг куллануны булдырмау һəм аңа каршы көрəш**

1. Спортта допинг куллануны булдырмау һəм аңа каршы көрəш федераль законнар нигезендə гамəлгə ашырыла.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең физик культура һəм спорт өлкəсендə вəкалəтле органы спортта допинг куллануны булдырмау һəм аңа каршы көрəш буенча эш оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затны Россия допингка каршы оешмасы, физик культура һəм спорт өлкəсендə федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясенең җыелма спорт командалары спортчыларын медик-биологик һəм медицина ягыннан тəэмин итүгə вəкалəтле федераль башкарма хакимият органы белəн хезмəттəшлектə билгели.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сəламəтлек саклау өлкəсендə вəкалəтле органы спортта допинг куллануны булдырмау һəм аңа каршы көрəш буенча эш оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затны Россия допингка каршы оешмасы һəм физик культура һəм спорт өлкəсендə федераль башкарма хакимият органы белəн хезмəттəшлектə билгели.».

